МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ Казан ш. БОЕРЫК

19.11.2013 №670-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатында

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Җир ресурсларын саклау бүлегенә (Н.А. Бережная) югарыда аталган Административ регламентка ярашлы рәвештә эшләрнең башкарылуын тәэмин итәргә.

3. Хокукый тәэмин итү бүлегенә (В.А.Тронин) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрергә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары Р.И. Камаловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр А.Г. Сидоров

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
19.11.2013 №670-п боерыгы
белән расланды

# ҖИР КИШӘРЛЕГЕН АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ БИЛГЕЛӘНЕШЕНДӘГЕ ҖИРЛӘРДӘН БАШКА КАТЕГОРИЯГӘ КҮЧЕРҮНЕ КИЛЕШТЕРҮ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮНЕҢ АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ

## Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затлар: юридик һәм физик затлар, шәхси эшкуарлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Министрлыкның урнашу урыны: Казан шәһәре, Павлюхин урамы, 75.

Министрлыкның эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Җәмәгать транспортында «Павлюхин» тукталышына кадәр килергә кирәк:

- 3, 4, 5, 12, 25, 27, 31, 37, 43, 47, 67, 69, 69а, 74, 74а, 77, 85 номерлы автобуслар;
- 6, 12 номерлы троллейбуслар.

Кертү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

1.3.2. Белешмәләр өчен Министрлыкның җир ресурсларын саклау бүлеге (алга таба – Бүлек): 267-68-37, 264-53-09.

1.3.3. Министрлыкның территориаль идарәләренең (алга таба – ТИ) белешмә адреслары һәм телефоннары кушымтада (белешмә).

1.3.4. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://www.eco.tatarstan.ru.http://www.eco.tatarstan.ru

1.3.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алучы, Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша.

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.eco.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);
Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән (телефон аша) мөрәҗәгать иткәндә;

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләренә бәйле мәгълүматлар Министрлыкның рәсми сайтында һәм Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында Бүлек белгече урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Җир кодексы 25.10.2001 ел, №136-ФЗ (алга таба – РФ Җир кодексы) (РФ законнары җыентыгы, 29.10.2001, №44, 4147 ст.);

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы 29.12.2004 ел, №190-ФЗ (алга таба – РФ Шәһәр төзелеше кодексы) (РФ законнары җыентыгы, 03.01.2005, №1 (1 өлеш), 16 ст.);

Россия Федерациясе Су кодексы 03.06.2006 ел, №74-ФЗ (алга таба – РФ Су кодексы) (РФ законнары җыентыгы, 05.06.2006, №23, 2381 ст.);

Россия Федерациясе Урман кодексы (алга таба – РФ Урман кодексы) (Российская газета, №277, 08.12.2006, РФ законнары җыентыгы, 11.12.2006, №50, 5278 ст.);

«Җир асты байлыклары турында» 21.02.1992 ел, №2395-1 Россия Федерациясе Законы (алга таба — РФ Законы №2395-1) (Россия Федерациясе халык депутатлары һәм Россия Федерациясе Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, 16, 834 ст.; Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, 10, 823 ст., 1999, 7, 2 ст., 2001, 21, 2061 ст., 3429; 2004, 35 ст., 3607; 2006, 17, 1941 ст.) 1778; 44, 4538; 2007, 27, 2008, 18, 18, 18 3418, 3420; 30, 3616; 2009, 1, 17; 29 ст., 3601; 52 ст., 6450; 2010, 21 ст., 2527; 2011, 30$ ст. 4567, 4570, 4572, 4590; 50, 7343, 7359 ст.);

«Табигый дәвалау ресурслары, дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлар турында» 23.02.1995 ел, №26-ФЗ федераль закон (алга таба – 26-ФЗ номерлы федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 27.02.1995, 9, 713 ст.);

«Махсус сакланыла торган табигать территорияләре турында» 14.03.1995 ел, №33-ФЗ федераль закон (алга таба – 33-ФЗ номерлы федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 20.03.1995, 12, 1024 ст.);

«Хайваннар дөньясы турында» 24.04.1995 ел, №52-ФЗ федераль закон (алга таба – 52-ФЗ номерлы федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 24.04.1995, №17, 1462 ст.);

«Атом энергиясеннән файдалану турында» 06.11.1995 ел, №170-ФЗ федераль закон (алга таба – 170-ФЗ номерлы федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 27.11.1995, 48, 4552 ст.);

«Экологик экспертиза турында» 23.11.1995 ел, №174-ФЗ федераль закон (алга таба – 174-ФЗ номерлы федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 27.11.1995, 48, ст. 4556);

«Халыкның радиацион куркынычсызлыгы турында» 09.01.1996 ел, №3-ФЗ федераль закон (алга таба – №3-ФЗ федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 15.01.1996, №3, 141 ст.);

«Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 30.03.1999 ел, №52-ФЗ федераль закон (алга таба – 52-ФЗ номерлы федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 05.04.1999, 14, 1650 ст.);

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 03.06.2006 ел, №74-ФЗ (алга таба – 7-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия газетасы, 6, 12.01.2002, Парламент газетасы, №9, 12.01.2002, РФ законнары җыентыгы, 14.01.2002, 2, 133 ст.);

«Җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү турында» 21.12.2004 ел, №172-ФЗ федераль закон (алга таба - 172-ФЗ федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 27.12.2004, 52 (1 өлеш), 5276 ст.);

«Күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастры турында» 24.07.2007 №221-ФЗ федераль закон (алга таба – 221-ФЗ номерлы федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 30.07.2007, №31, 4017 ст.);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру» 06.07.2010 №210-ФЗ федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) (Российская газета, 168, 30.07.2010, РФ законнары җыентыгы, 02.08.2010, 31, 4179 ст.);

«Җитештерү процессларын башкарганда, шулай ук транспорт магистральләрен, труба үткәргечләрен, элемтә линияләрен һәм электр тапшыргычларын эксплуатацияләгәндә, хайваннар дөньясы объектларының үлүен булдырмау буенча таләпләр турында» 13.08.1996 ел, №997 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба – 997 номерлы РФ Хөкүмәте карары) (РФ законнары җыентыгы, 09.09.1996, 37, 4290 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Атом-төш җайланмаларын, радиация чыганакларын һәм саклау пунктларын урнаштыру һәм кору турында карарлар кабул итү кагыйдәләре турында» 1997 елның 14 мартындагы 306 номерлы карары (алга таба - 306 номерлы РФ Хөкүмәте Карары) N(РФ законнары җыентыгы, 24.03.1997, №12, ст. 1442);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Файдалы казылма ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын һәм файдалы казылма төрләре һәм җир асты байлыкларыннан файдалану төрләре буенча җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшләр башкаруга бүтән проект документларын әзерләү, килештерү һәм раслау турында нигезләмә раслау хакында» 2010 елның 3 мартындагы 118 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 118 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №10, 1100 статья);

2009 елның 15 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Экология Кодексы (алга таба – ТР Экология кодексы) (Татарстан Республикасы, №10, 20.01.2009);

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба – 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, №11-12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, №2 (2); 2001, №12; 2004, №7 (I өлеш); 2005, N4 (1 өлеш); 2008,№; 2009, №9-10);

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламентын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте турында нигезләмә раслау хакында» 2005 елның 5 декабрендәге 563 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 563 номерлы карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 21.12.2005, 47-48, 0985 ст.);

«Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» (алга таба — 325 номерлы ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 27.07.2005, №28, 0654 ст.);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының Татарстан Республикасы вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын тәэмин итә торган Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре исемлеген һәм Татарстан Республикасында дәүләт мөлкәтен үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2005 елның 25 августындагы 416 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба - 416 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары) N(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 14.09.2005, №33-34, ст. 0778);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турында үтенечнамә формасын һәм аңа кушып бирелә торган документлар составын раслау турында» 2006 елның 25 октябрендәге 523 номерлы карары (алга таба - 523 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 08.11.2006, №41-42, 1061 ст.);

«Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» (алга таба — 38 номерлы ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 21.02.2007, №8, ст. 0330);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе турында нигезләмә раслау хакында» 2008 ел, 18 апрель,

246 нчы карары (алга таба – 246 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 21.05.2008, 19, 0702 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба – 880 номерлы ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 2010, №46, 2144 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә үзләренә бүлеп бирелгән тау бүлемтекләре чикләрендә файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару белән шөгыльләнүче яисә берләштерелгән лицензия буенча файдалы казылмаларны геологик өйрәнүне, разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыручы җир асты байлыкларыннан файдаланучылар тарафыннан шәхси производство һәм технологик ихтыяҗлар өчен гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару тәртибен раслау турында» 2011 елның 21 декабрендәге 1042 номерлы карары (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 1042 номерлы карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2012, №4, 0120 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару, җир асты корылмаларын төзү һәм көнкүреш коеларын һәм скважиналарын ясау тәртибен раслау турында» 2012 елның 29 февралендәге 171 номерлы карары (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 171 номерлы карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2012, №26, 0859 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасының ягулык салу комплексы объектларында экологик куркынычсызлыкны һәм ресурсларны саклауга юнәлтелгән чараларны тормышка ашыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 06.02.2013 152-р боерыгы (алга таба - ТР МК №152-р боерыгы) (ТР МК карарлары, боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы) (19.02.2013);

Радиоактив калдыклар белән эш итүнең санитар кагыйдәләре (СПОРО 2002) СП 26.6.1168-02 (алга таба – СП 2.6.6.1168-02) (Российская газета, №237, 18.12.2002, Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, №3, 20.01.2003);

Төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре 2.07.01-89 «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү» (алга таба – СНиП 2.07.01-89) (2011 елның 20 маеннан гамәлгә кертелгән СП 42.13330.2011) «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү. СНиП 2.07.01-89» актуаль редакциясе, РФ Төбәк министрлыгының 28.12.2010 №820 боерыгы белән расланган);

«Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчәргә яраклы суүткәргечләрнең санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» (алга таба – СанПиН 2.1.4.1110-02) «Российская газета», №81, 08.05.2002, «Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене», №19, 13.05.2002;

«Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП санитар кагыйдәләре (алга таба – СП 2.1.5.1059-01) («Российская газета», №172, 05.09.2001, «Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене», №38, 17.09.2001);

«Җир асты суларын саклауга гомуми таләпләр» (алга таба – ГОСТ 17.1.3.06-82) дәүләт стандарты;

«Җир эшләре башкарганда туфракның уңдырышлы катламын саклауга карата таләпләр» дәүләт стандарты (алга таба – ГОСТ 17.4.3.02 - 85);

«Җирләрне рекультивацияләүгә гомуми таләпләр» дәүләт стандарты (алга таба – ГОСТ 17.5.3.04-83);

РД 153-392-080-01 «Автозаправка станцияләрен техник эксплуатацияләү кагыйдәләре».

2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбенең атамасы | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы | Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүне килештерү | РФ Җир кодексының 10, 29, 30, 31, 78 ст.;<br>7-ФЗ номерлы федераль законның 6, 34 ст.;<br>172-ФЗ номерлы федераль законның 2, 7 ст.;<br>325 номерлы ТР МК карары;<br>523 номерлы ТР МК карары |
| 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | 325 номерлы ТР МК карары |

| | | |
|---|---|---|
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүне килештерү турында бәяләмә.<br>Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүне килештерүдән баш тарту турында бәяләмә. | РФ Җир кодексының 2 п. 12 ст., 1 п. 13, ст. 1, 40, ст. 42, ст. 2 п. 56, ст. 3 п. 94, п. 9, 10 ст. 85, ст. 88, п.3. ст. 96 ; РФ Су кодексының10 ст., 85 ст., 88 ст., 96 ст. п..; 6 ст., 42 ст., 43 ст. 2 п., 50 ст. 2 п. 52 ст., 1, 4, 5 ст., 59 ст. 5 п., 60 ст., 64 ст., 65 ст.;<br>7-ФЗ номерлы федераль законның 61 ст. 2 п.;<br>РФ Урман кодексының 12 ст. 4 п., 102 ст. 4, 5 п.;<br>52-ФЗ номерлы федераль законның 12, 22 ст.;<br>3-ФЗ номерлы федераль законның 6 статьясындагы дүртенче абзацы;<br>172-ФЗ номерлы федераль законның 10-12 ст.;<br>174-ФЗ номерлы федераль законның 11, 12 ст.;<br>221-ФЗ номерлы федераль законның 7 ст., 12 п.; |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты | Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне килештерү буенча Министрлык бәяләмәсе – гариза кергән көннән алып җиде эш көне эчендә. | |
| 2.5. Закон яки башка төрле норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге | Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүне килештерү өчен тәкъдим итәргә тиешле документлар исемлеге, әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлардан тыш, 1 нче кушымтада китерелгән.<br>Документлар бер нөсхәдә тапшырыла. | РФ Җир кодексының 30, 31 ст.; ТР МК №523 карары |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган башка органнар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | 1. Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләр бердәм дәүләт реестрыннан җир кишәрлегe хокуклары турында өземтә.<br>2. Җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе, җир кишәрлегенең кадастр паспорты.<br>3. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге сорала торган җирләрне күрсәтеп, җир кишәрлегенең урынын билгеләргә мөмкинлек бирә торган план-картография материалы, торак пунктларның чикләрен һәм исемнәрен, гидрография элементларының, автомобиль юлларының һәм башка линия объектларының төрләрен күрсәтеп, 1:25000 яисә 1 : 10000 масштабында.<br>4. Вәкаләтле органнарның җир кишәрлеген сайлап алу актын кушып, объектны урнаштыру урынын алдан килештерү турында карары (әгәр җир участогы дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдән объект урнашу урынын алдан килештерү белән бирелсә).<br>5. Файдалы казылма ятмаларын эшкәрткәндә, әлеге исемлеккә өстәмә рәвештә бирелә:<br>- тау токымының чикләрен план-картографик материалга (терәк, параметрик, структур, эзләү, бәяләү һәм разведкалау скважиналарын урнаштырудан тыш) урнаштыру акты.<br>6. Махсус сакланыла торган табигать территорияләре турында мәгълүмат.<br>7. Дәүләт аучылык тыюлыклары булу турында мәгълүмат.<br>Мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән документларны мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы.<br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан документларны тапшырмау дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тормый | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда алар белән килештерү таләп ителә торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителә | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелә торган документларда килештерелмәгән | |

| | | |
|---|---|---|
| | төзәтмәләр булу | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге 3 нче кушымтасында китерелгән | РФ Җир кодексының 4, 5 ст., 56, 4 ст. 2 п., 79, 10, 12 ст. 9, 12 п., 85 ст. 2, 4 п., 88 ст. 3 п., 90 ст. 3 п., 94 ст., 5, 7 п. п., 95 ст. п., 96 ст. п., 4 п., 97 ст. 5 п., 98 ст. 5 п., 100 ст. 1 п., 102 ст. 2 п.;<br>7-ФЗ номерлы федераль законның 3 ст., 4 п., 58 ст., 59 ст. 2 п., 60 ст. 1 п., 61 ст. 2 п., 62 ст.<br>РФ Урман кодексының 102 ст. 12, 2, 4, 5 п.; РФ Су кодексының 65 ст.;<br>33-ФЗ номерлы федераль законның 9 ст. 1 п., 21 ст. 4 п., 24 ст. 1 п., 27 ст. 1 п., 29 ст. 1 п., 32 ст. 1 п.;<br>26-ФЗ номерлы федераль законның 16 ст. 3 п.; |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | 845-р номерлы ТР МК боерыгы |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләүнең күләмен хисаплау методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри булган дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү юк | 675 номерлы ТР МК карары |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Мөрәҗәгать итүче тарафыннан үзен кабул итүне (хезмәт күрсәтелүне) көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артып китәргә тиеш түгел. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры | Гариза кергән көннән бер көн эчендә | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.14 . Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр | Катнашу урыны түбәндәгеләр белән җиһазландырылган:<br>һаваны кондиционерлау системасы белән;<br>янгынга каршы система белән һәм янгын сүндерү системасы белән;<br>Татарстан Республикасының дәүләт интеграцияле телекоммуникация системасына тоташтырылган мәгълүмат киоскысы белән.<br>Гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүче район һәм шәһәр округларының башкарма комитетларында гариза бирә ала (4 нче кушымта) | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:<br>Министрлык бүлмәләренең җәмәгатьчелек транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге Министрлыкның мәгълүмат ресурсларында, бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында тулы мәгълүмат булуы;<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>1) кабул итү срокларын үтәү документларны карау тәртибе;<br>2) Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытының саклануы;<br>3) дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан кылынган административ регламентны (прецедентларның, шикаятьләрнең) хезмәт күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларның гомуми санына карата мөнәсәбәте) бозуга прецедентларның (нигезләнгән шикаятьләрнең) булуы.<br>Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәктә күрсәтелгән очракта, документларны кабул итү һәм бирү күпфункцияле үзәк белгече тарафыннан гамәлгә ашырыла. | |
| 2.16. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон рәвештәге гаризаны, алга таба документларның төп нөсхәләрен тапшыру юлы белән, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшыру мөмкинлеге бар. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада да үтәү үзенчәлекләре

3.1. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүне килештерү (килештерүдән баш тарту) турында бәяләмә әзерләү; 5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге Блок-схемасы 5 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр бирү.

Мөрәҗәгать итүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Министрлыкның җир ресурсларын саклау бүлегенә телефон, язмача һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Министрлыкның җир ресурсларын саклау бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән, бирелә торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен башка мәсьәләләр буенча консультацияләр бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: составы, тапшырыла торган документлар формасы һәм бәяләмә алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүне килештерү буенча бәяләмә бирү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) шәхсән кәгазьдә, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша йә почта аша заказлы почта аша тапшыру турында белдерү кәгазе белән, әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны үтәүне тикшереп тору бүлегенә, 1 нче кушымта нигезендә, бәяләмә алу ысулын күрсәтеп (кәгазьдә, почта аша, тапшыру турында уведомление белән, электрон почта аша) гариза тапшыра (җибәрә).

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә этәргеч булган рәсми мөрәҗәгатьне тапшыру мөрәҗәгать итүчегә документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтүне таләп итми.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар.

3.3.2. Министрлыкның документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге белгече барлык кирәкле документларның булуын һәм аларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә.

Әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, документларны үтәүне контрольдә тоту бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәүдән баш тарту өчен нигезләрнең булуы турында хәбәр итә һәм аңа документларны кире кайтара.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Министрлыкның документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге белгече башкара:

гаризаны электрон журналда теркәү өчен документлар кабул итү; мөрәҗәгать итүчегә почта аша җибәрү (аның теләге белән), кирә торган номерда бирелгән документларны кабул итү датасы турында тамгалы гариза күчермәләре; мөрәҗәгать итүченең гаризасын һәм документларын карау өчен Министрлыкның җир ресурсларын саклау бүлегенә җибәрү.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Министрлыкның җир ресурсларын саклау бүлегенә җибәрелгән гариза һәм документлар; мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Министрлыкның җир ресурсларын саклау бүлеге башлыгы авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүне килештерү буенча документларны карау һәм бәяләмә әзерләү буенча җаваплы башкаручыны билгели (алга таба - бәяләмә проекты).

Процедураның нәтиҗәсе: Министрлыкның җир ресурсларын саклау бүлеге белгеченә җибәрелгән документлар.

Министрлыкның җир ресурсларын саклау бүлеге белгече:

ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон формада сораулар формалаштыра һәм җибәрә:

Объектны урнаштыру урынын алдан килештерү турында карар бирү турында муниципаль районның (шәһәр округының) башкарма комитетына, җир кишәрлеген сайлау акты кушымтасы белән (җир кишәрлеге дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән объектны урнаштыру урынын алдан килештереп бирелгән очракта);

җир кишәрлегенең урынын билгеләргә мөмкинлек бирә торган, сорала торган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне күрсәтеп, торак пунктларның чикләрен һәм исемнәрен, җирләрнең төрләрен, гидрография элементларын, автомобиль юлларын һәм башка линия объектларын күрсәтеп, планлы-картографик материал, 1:25000 якм 1:10000 масштабында;

Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсенә – күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан җир кишәрлегенә хокуклар турында өземтә бирү хакында;

«Росреестрның Федераль кадастр палатасы» ФДБУнең Татарстан Республикасы филиалына – җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе, җир кишәрлегенең кадастр паспорты бирү турында;

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына – җир кишәрлегендә махсус саклана торган табигать территорияләре турында мәгълүмат бирү турында;

Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсенә – җир кишәрлегендә дәүләт аучылык тыюлыклары булу турында мәгълүмат бирү турында.

Файдалы казылма ятмаларын эшкәрткәндә:

